КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 18 май г.Казань № 463

Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкта бер сутый җир мәйданыннан алынган җиләк-җимешләрне һәм продукцияне реализацияләүдән чиста керемнең бер айга кыйммәти чагылыштагы нормативы турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җир мәйданының бер сотыеннан шәхси ярдәмче хуҗалыкта алынган җимешләрне һәм продукцияне реализацияләүдән чиста керемнең кыйммәти чагылыштагы айлык нормативы турында» 2011 ел, 5 июль, 538 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1 Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкта бер сутый җир мәйданыннан алынган җиләк-җимешләрне һәм продукцияне реализацияләүдән чиста керемнең бер айга кыйммәти чагылыштагы нормативын 385,0 сум күләмендә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җир мәйданының бер сотыеннан шәхси ярдәмче хуҗалыкта алынган җимешләрне һәм продукцияне реализацияләүдән чиста керемнең кыйммәти чагылыштагы айлык нормативы турында» 2021 ел, 21 май, 356 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин